*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*



# Чишмә башы

Ноябрь, 2024 ел

№1




***Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар***

## *Бу санда:*

- “Күзгә калейдоскоп” күргәзмәсе
- Бакчабызда “Уңыш ” бәйрәме
- “Халыклар бердәмлеге көне” бәйрәме
- “Татарча диктант” акциясендә актив катнаштык
- Татарстан Республикасында яшәвебез белән горурланабыз!
- ГТО нормалары тапшыру
- “Мин татарча өйрәнәм” олимпиада нәтиҗәләре
- ГПКЗ «Ашит» хезмәткәрләре бездә кунакта
- Әниләр көненә багышланган бәйрәме иртәсе

## *Ноябрь аенда:*

4 ноябрь - Халыклар бердәмлеге көне.

6 ноябрь-Татарстан Республикасы Конституциясе көне.

12 ноябрь—Песнәкләр көне

22 ноябрь-Уллар көне.

24 ноябрь (айның соңгы якшәмбесе) — Әниләр көне











Көз көне җир өстенә коелган алтын яфраклар өстеннән йөрү, үзенә бер рәхәтлек бирә. Әгәр ул яфракларны өйгә алып керсәң, алар шаккаттыргыч әйберләргә әйләнергә мөмкин. Моның өчен бераз фантазия һәм илһам гына кирәк.

Һәр көздә бакчабызда табигый материалдан, яшелчә һәм җиләк-җимешләрдән балалар һәм аларның әти-әниләре белән күргәзмә үткәрү традициягә әйләнде. Әти-әниләр һәм балалар «Көзге колейдоскоп» күргәзмәсендә актив катнаштылар, үзләренең фантазияләрен һәм иҗади сәләтләрен күрсәттеләр.

Барлык эшләнмәләр искиткеч килеп чыкты.

Бакчабызда "Көзге уңыш" бәйрәме булып узды.

Бәйрәмдә "Көзге калейдоскоп" күргәзмәсенә матур эшләнмәләр алып килгән балаларга дипломнар тапшырылды. Бәйрәм матур шигырьләр, җыр-бию, уеннар белән үрелеп барды.









Арча муниципаль районының "Арча 6нчы номерлы урта гомуми белем мәктәбендә "Мин татарча өйрәнәм" олимпиадасында катнашкан әзерлек төркеменә йөрүче балаларны бүләкләү тантанасы булып узды. Иванова Милана, Кодирова Зәйнәб II дәрәҗәдәге , Шакирова Зәринә I дәрәҗәдәге дипломнар белән бүләкләнделәр. Котлыйбыз!!!





Мөхәммәтҗанов Ралиф, Кодирова Зәйнәб, ГТО нормаларын яхшы нәтиҗәләргә тапшырып, I урын яуладылар. Чын күңелдән котлыйбыз!!!






4 ноябрь - Халыклар бердәмлеге көне.
Һәрберегезне шушы матур мәгънәгә ия бәйрәм белән котлыйбыз! Килер көннәребез аяз, имин, тормышларыбыз мул булсын!

















1992 елда Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү республиканың хәзерге хокукый системасын булдыруда әһәмиятле роль уйнады.

Без Татарстан Республикасында яшәвебез белән горурланабыз.

Татарстан Республикасы Конституциясе көне белән!





Татарча диктант" акциясенә кушылдык





***Песнәк***

***Бакчадагы җимлегемә,***

***Килеп кунды бер песнәк.***

***Аны күргәч алып чыктым,***

***Ашарына мин икмәк.***

***Көн саен мин ярма салам,***

***Кошлар җим чүпли иртән.***

***Ә мин алар тавышында,***

***Гүя рәхмәт ишетәм.***

***Зилә Гыйльманова***



Арча муниципаль районы төньяк территориаль оешмасыннан килгән кунаклар белән җылы очрашу булып узды. Кунаклар балаларга экология буенча кызыклы табышмаклар әйтеп, мавыктыргыч мәгълүматлар җиткереп, бүләкләр тапшырдылар.







Әниләребезнең күңел җылысы биреп эшләнгән
“Әниемнең алтын куллары“кул эшләре күргәзмәсе оештырылды



Әниләрнең назы белән
Без керәбез һәр көнгә.
Кояш кирәк җир йөзенә
Әни кирәк һәркемгә!

Әни! Һәркем өчен иң изге, иң кадерле зат. Бу якты дөньяга килгәч тә нарасыен йомшак куллары белән сыйпап, ак биләүгә биләүче, елаганда юатучы, татлы йокыдан иркәләп уятучы, яшәргә көч-дәрт бирүче бит ул безнең газиз әниләр!

Балагызның берәве сез,
Гаиләнең йөрәге сез.
Иминлекнең терәге сез.
Һәркемнең кирәге сез.


Бакчабызда әниләр көне уңаеннан әниләр һәм балалар белән берлектә “Сәламәтлек-зур байлык” исеме астында бәйрәм иртәсе үткәрдек. Бәйрәм балаларның матур шигырьләре, җырлары, биюләре белән үрелеп барды. Әниләр балалары белән бергә командаларга бүленеп, үзләренең тапкырлыкларын, җитезлекләрен күрсәтеп, уеннарда, ярышларда актив катнаштылар.






















***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Хөсәенова Р.Н., Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары***: *Гафурова Р.А., Шагиева А.К., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР,Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*